**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **08.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Үчәлле авыл җирлеге составына керүче
Текмәле авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Текмәле авылы Ишкәй урамы буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Текмәле авылы территориясен куаклардан, чүп үләннәреннән чистарту һәм тоташ гербицид белән химик эшкәртү;
- Текмәле авылында юлларны кардан чистарту;
- Текмәле авылында җәйге вакытта территорияне чабу;
- Текмәле авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Текмале авылында ике телдә урам күрсәткечләрен һәм торак йортлар өчен номерларны сатып алу (әзерләү).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина